**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**САРМАШ-БАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№ 94** **06.04.2018**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында" нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 20 февралендәге 75 номерлы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында" нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 20 февралендәге 75 номерлы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары реестрына кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Л.В. Хөснетдинова**

Зәй муниципаль районы Сармаш-
Баш авыл җирлеге Советының 2018
елның 06 апрелендә кабул ителгән
9 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 11 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктындагы 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча - ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә әзерлек юнәлеше белгечлеге буенча кимендә биш ел эш стажы.

Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) вазыйфасын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре - кимендә ике ел яки кимендә өч ел.